Л.И. Сәүбәнова Ә.С. Тайсин

ГЕОГРАФИЯ

ТЕСТЛАР



7 сыйныф

«Мәгариф» нәшрияты

Л. И. Сәүбәнова Ә. С. Тайсин

МАТЕРИКЛАР ҺӘМ ОКЕАННАР ГЕОГРАФИЯСЕ БУЕНЧА ТЕСТЛАР

Татар урта гомуми белем мәктәбенең
7 нче сыйныфы өчен

Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән

Казан
«Мәгариф» нәшрияты
2002

УДК 373.167.1
ББК 74.262.6я72
С93

Охраняется законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Сәүбәнова Л. И., Тайсин Ә. С.

С93 Материклар һәм океаннар географиясе буенча тестлар: Татар урта гомуми белем мәкт. 7 нче с-фы өчен.— Казан: Мәгариф, 2002.— 87 б.

ISBN 5-7761-0904-3

Бу ярдәмлектә 7 нче сыйныф укучылары өчен материклар һәм океаннар географиясе курсы буенча тестлар тупланган. Алар һәр тема буенча укучыларның белемнәрен тикшерергә һәм курсның йомгаклау дәресләрен үткәрергә ярдәм итәчәк.

БЗ—9(68) — 55 —2002/2003

ISBN 5-7761-0904-3 © «Мәгариф» нәшрияты, 2002

I нче вариант

1. Мәйданы буенча иң зур океан — ...

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
2. Атлантик океан.

2. Бу океанның нигезендә өч литосфера плитасы урнашкан: Һинд-Австралия, Антарктика һәм Африка. Бу — ...

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.

3. Кайсы океан көнбатыштан — Төньяк һәм Көньяк Америка, көньяктан — Антарктида, ә көнчыгыштан Евразия һәм Африка материкларының яр буйларын юа?

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

4. Кайсы океан төбенең $^1/_3$ өлешеннән артыграк мәйданын киң шельф алып тора?

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

5. Төньяк Атлантик агымын барлыкка китерүгә төп сәбәп — ...

1. Даими җилләр.
2. Океан төбе рельефы.
3. Материкларның яр буе сызыклары.

6. Бенгела агымы — ...

1. Җылы агым.
2. Салкын агым.

7. Океанда су өслегенең температурасы үзгәрүнең төп сәбәбе — ...

1. Җир өстендә атмосфера басымы поясларының урнашуы.
2. Суларның тозлылыгы.
3. Кояш нурларының төшү почмагы.

8. Сез океаннар аша дөнья тирәли сәяхәткә чыктыгыз. Сәяхәтнең башлангыч һәм ахыргы ноктасы булып, Төньяк Боз океанының Баренц диңгезе ярында урнашкан Мурманск порты тора. Бирелгән маршрутларның кайсы кыскарак?

1. Мурманск шәһәре — Лондон шәһәре (Бөек Британия утравы) — Панама каналы — Филиппин утраулары — Шри Ланка утравы — Аден култыгы — Сүәеш каналы — Гибралтар бугазы — Лондон шәһәре — Мурманск шәһәре.

2. Мурманск шәһәре — Лондон шәһәре (Бөек Британия утравы) — Магеллан бугазы — Сидней (Көньяк Африка) — Лондон шәһәре — Мурманск шәһәре.

2 нче вариант

1. Кайсы океан мәйданы буенча дөньяда өченче урынны алып тора?

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

2. Бу океан төбендә җир тетрәүләр һәм вулканнар ату бик еш була. Океан чикләрендә урнашкан вулканнар һәм вулканик утраулар «Утлы боҗра» хасил итәләр. Бу океан — ...

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

3. Австралиядән кала биш материкның ярларын кайсы океан сулары юа?

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

4. Иң салкын океан — ул ...

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

5. Көнчыгыш Австралия агымы барлыкка килүгә төп сәбәп — ...

1. Даими җилләр.
2. Океан төбе рельефы.
3. Материкларның яр буе сызыклары.

6. Перу агымы — ...

1. Җылы агым.
2. Салкын агым.

7. Ни өчен тропик киңлекләрдә Тын океан суының тозлылыгы экваториаль киңлекләрдәге суныкыннан артыграк?

1. Температура үзгәрә.
2. Явым-төшем күләме кими.

8. Сез океаннар аша дөнья тирәли сәяхәткә чыктыгыз. Сәяхәтнең башлангыч һәм ахыргы ноктасы — Һинд океанының төньягында урнашкан Калькутта порты (Һиндстан). Бирелгән маршрутларның кайсы кыскарак?

1. Калькутта шәһәре — Кейптаун шәһәре (Көньяк Африка) — Лондон шәһәре (Бөек Британия утравы) — Мурманск шәһәре — Тикси шәһәре (Лаптевлар диңгезе) — Беринг бугазы — Магеллан бугазы — Кейптаун шәһәре — Мадагаскар утравы — Калькутта шәһәре.
2. Калькутта шәһәре — Аден култыгы — Сүәеш каналы — Гибралтар бугазы — Баффин диңгезе — Бофорт диңгезе — Беринг бугазы — Токио шәһәре (Япон утраулары) — Көньяк Кытай диңгезе — Зонд бугазы — Калькутта шәһәре.

3 нче вариант

1. Мәйданы буенча иң кечкенә океан — ...

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

2. Иң җылы океан — ...

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

3. Кайсы океан бары тик ике материкның гына ярларын юмый?

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

4. Атлантик океанның көнчыгыш өлешендә төньяк субтропик табигый географик пояс чикләрендә урнашкан бу диңгез өч дөнья кисәгенең яр буйларын юа. Бу диңгез — ...

1. Кариб диңгезе.
2. Уэдделл диңгезе.
3. Урта диңгез.

5. Көньяк пассат агымын барлыкка китерә торган төп сәбәп — ул ...

1. Даими җилләр.
2. Океан төбе рельефы.
3. Материкларның яр буе сызыклары.

6. Көнбатыш җилләр агымы — ...

1. Җылы агым.
2. Салкын агым.

7. Цунами барлыкка килүгә төп сәбәп — ...

1. Океан агымнары.
2. Диңгез суларының температурасы.
3. Җил.
4. Җир тетрәү.

8. Сез океаннар аша дөнья тирәли сәяхәткә чыктыгыз, ди. Сәяхәтнең башлангыч һәм ахыргы ноктасы — Атлантик океанның төньяк-көнчыгышында урнашкан Лондон шәһәре (Бөек Британия утравы). Бирелгән маршрутларның кайсы кыскарак?

1. Лондон шәһәре — Мурманск шәһәре — Тикси шәһәре (Лаптевлар диңгезе) — Беринг бугазы — Магеллан бугазы — Кейптаун шәһәре (Көньяк Африка) — Мадагаскар утравы — Аден култыгы — Кызыл диңгез — Сүәеш каналы — Гибралтар бугазы — Лондон шәһәре.

2. Лондон шәһәре — Канар утраулары — Кейптаун шәһәре (Көньяк Африка) — Мадагаскар утравы — Зонд бугазы— Джакарта шәһәре — Беринг бугазы — Бофорт диңгезе —Баффин диңгезе — Девис бугазы — Лондон шәһәре.

4 нче вариант

1. Кайсы океан мәйданы буенча дөньяда икенче урынны алып тора?

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

2. Кайсы океанның күпчелек өлеше бер литосфера плитасында урнашкан?

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

3. Кайсы океан ике материкның гына яр буйларын юа?

1. Тын океан.
2. Төньяк Боз океаны.
3. Һинд океаны.
4. Атлантик океан.

4. Бу диңгез Һинд океанында иң яшь диңгез (галимнәр фикере буенча аның яше 20 млн ел). Океан белән тоташа торган диңгезләр арасында бу диңгез иң тозлы (42‰). Ул ике дөнья кисәген аера һәм кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә Һинд океаны белән генә түгел, ә Атлантик океан белән дә (Суэеш каналы аша) тоташа ала. Бу ...

1. Гарәп диңгезе.
2. Кызыл диңгез.
3. Девис диңгезе.

5. Гвиана агымын барлыкка китерә торган төп сәбәп — ул ...

1. Даими җилләр.
2. Океан төбе рельефы.
3. Материкларның яр буе сызыклары.

6. Бразилия агымы — ул ...

1. Җылы агым.
2. Салкын агым.

7. Полюстан экваторга таба дөнья океаны су өслегенең температурасы ничек үзгәрә?

1. Төшә.
2. Үзгәрми.
3. Күтәрелә.

8. Сез океаннар аша дөнья әйләнә сәяхәткә чыктыгыз, ди. Сәяхәтнең башы һәм ахыргы ноктасы — Тын океанның көнбатышында Япон диңгезе яр буенда урнашкан Владивосток шәһәре. Бирелгән маршрутның кайсы кыскарак?

1. Владивосток шәһәре — Беринг бугазы — Лаптевлар диңгезе — Мурманск шәһәре — Лондон шәһәре (Бөек Британия утравы) — Гибралтар бугазы — Сүәеш каналы — Кызыл диңгез — Зонд бугазы — Көньяк Кытай диңгезе — Япон диңгезе — Владивосток шәһәре.
2. Владивосток шәһәре — Беринг бугазы — Бофорт диңгезе — Баффин диңгезе — Лабрадор ярымутравы — Кейптаун шәһәре (Көньяк Африка) — Перт шәһәре (көньяк-көнбатыш Австралия) — Сидней шәһәре (көньяк-көнчыгыш Австралия) — Яңа Гвинея утравы — Япон диңгезе — Владивосток шәһәре.

1 нче вариант

1. Атамага географик урынын тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик урыны:
1. Рас-Энгел борыны.	А. Африканың иң көньяк ноктасы.
2. Рас-Хафун борыны.	Б. Африканың иң көнбатыш ноктасы.
3. Альмади борыны.	В. Африканың иң көнчыгыш ноктасы.
4. Энә борыны.	Г. Африканың иң төньяк ноктасы.

2. Түбәндәге тау системалары арасында нинди таулар яңа җыерчыклану өлкәсенә туры килә?

1. Атлас таулары.
2. Дракон таулары.
3. Эфиопия таулыгы.

3. Африка территориясендә нинди рельеф формалары өстенлек итә?

1. Түбәнлекләр.
2. Яссы таулыклар.
3. Таулар.

4. Африка материгында иң биек тау түбәсе — ...

1. Кения тавы.
2. Килиманджаро вулканы.
3. Рас-Дашэн тавы.

5. Дракон тауларының көнчыгыш битләрендә климатның күп өлеше өчен түбәндәге үзенчәлекләр хас: ТҺМ, уртача $t_г = +24°C$, $t_и = +16°C$, еллык явым-төшем күләме 500 мм дан 2000 мм га кадәр һәм ул ел буена тигез бүленә, ә җәй көне — максималь була. Бу — ...

1. Субэкваториаль климат.
2. Дымлы тропик климат.
3. Тропик чүлләр климаты.

6. Гыйнвар белән чагыштырганда Африканың бу чүлендә июль салкынрак. Бу чүл — ...

1. Сахара.
2. Намиб.

7. Субтропик урта диңгез климаты өлкәсендә явым-төшемнәр кайсы сезонда күбрәк була?

1. Җәй көне.
2. Кыш көне.

8. Африка материгында иң тирән күл — ...

1. Виктория күле.
2. Ньяса күле.
3. Танганьика күле.

9. Конго елгасы бассейны һәм Гвинея култыгы буйлап урнашкан табигый географик зона өчен түбәндәге үзенчәлекләр хас: экваториаль климат, кызгылт сары ферралит туфраклар, үсемлекләр (агачлар) ярусларга бүленеп үсәләр һәм төрле хайваннар яши. Бу — ...

1. Дымлы экваториаль урманнар (гилея) зонасы.
2. Саванналар һәм сирәк урманнар зонасы.
3. Тропик чүлләр зонасы.

10. Бу илне еш кына «зур ярылулар иле» дип атыйлар. Монда Африканың иң биек тау түбәсе булган Килиманджаро вулканы, Виктория күленең көньяк өлеше, Танганьика күленең көнчыгыш өлеше урнашкан. Монда дөньяның иң атаклы тыюлыгы — Серенгети да бар. Башкаласы — Дар-эс-Салам шәһәре. Бу ил — ...

1. Эфиопия.
2. Заир.
3. Танзания.

2 нче вариант

1. Атамага тиешле географик урынын тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик объект:
1. Гвинея	А. ярымутравы.
2. Мозамбик	Б. култыгы.
3. Сомали	В. утравы.
4. Занзибар	Г. бугазы.

2. Африка материгының зур өлеше урнашкан геологик нигез — ...

1. Борынгы платформа тәшкил итә.
2. Борынгы җыерчыклану өлкәләре.

3. Көнчыгыш Африкада тау системаларын барлыкка китерүче төп сәбәп — ...

1. Яңа җыерчыклану өлкәләре барлыкка килү.
2. Литосфера плиталары аерылу.

4. Африканың иң төньяк һәм көньяк өлешләре климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: җәй көне — ТҺМ, коры, кыш көне — УҺМ, дымлы, уртача $t_к = +8... +12°C$, $t_{ию} = +24... +27°C$ еллык явым-төшем күләме 600—700 мм (кыш көне — максимум, җәй көне — минимум). Бу климат — ...

1. Субтропик урта диңгез климаты.
2. Субэкваториаль климат.
3. Дымлы тропик климат.

5. Июль белән чагыштырганда бу Африка чүлендә гыйнварда җылырак. Бу чүл — ...

1. Ливия. 2. Намиб.

6. Явым-төшемнең күп булуы нинди атмосфера басымы өлкәләре белән бәйле?

1. Түбән басым өлкәләре.
2. Югары басым өлкәләре.

7. Африканың иң тулы сулы елгасы — ...

1. Нил. 2. Замбези. 3. Конго.

8. Африкада мәйданы буенча иң зур күл — ...

1. Чад күле.
2. Виктория күле.
3. Ньяса күле.

9. Африкада кайсы табигый географик зона өчен түбәндәге үзенчәлекләр хас: ул материкның 40 % ка якын мәйданын алып тора, субэкваториаль климат, кызгылт көрән туфраклар, үләннәр капламы бик бай. Бу — ...

1. Дымлы экваториаль урманнар (гилея) зонасы.
2. Саванналар һәм сирәк урманнар зонасы.
3. Тропик чүлләр зонасы.

10. Бу илнең исеме аның көнбатыш өлешендә урнашкан чүл исеменә бәйле. Монда файдалы казылмалардан уран һәм алмаз күп. Илдә күп кенә үсемлекләрнең һәм хайваннарның борынгы төрләре сакланып калган. Бу вельвичия, Кап таулары сукыр тычканы, долгоног, алтынсу сукыр тычкан h. б. Илнең төньягында дөньяның иң зур тыюлыкларыннан саналган Этош тыюлыгы урнашкан. Бу тыюлыкта кара мөгезборыннар, тау зебралары, балашарлар яши. Башкаласы — Виндхук шәһәре. Бу ил — ...

1. Ботсвана.
2. Намибия.
3. Ангола.

3 нче вариант

1. Атамага географик объектны тәңгәл китереп җавап бирегез.

Атама:	Географик объект:
1. Аден	А. диңгез.
2. Гибралтар	Б. утравы.
3. Кызыл	В. култыгы.
4. Сан-Томе	Г. бугазы.

2. Виктория шарлавыгын кем ачкан?

1. В. Юнкер.
2. Д. Ливингстон.
3. Г. Стенли.

3. Африкада урнашкан нинди таулар Һималай һәм Альп таулары белән якынча бер үк вакытта (бертөрле җыерчыклану чорында) барлыкка килгән?

1. Эфиопия таулыгы.
2. Дракон таулары.
3. Атлас таулары (төньяк өлеше).

4. Африканың кайсы районында хәзер дә ата торган һәм сүнгән вулканнарны күрергә мөмкин?

1. Кап тауларында.
2. Дракон тауларында.
3. Көнчыгыш Африка яссы таулыгында.

5. Гвинея култыгы яр буйлары климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: уртача еллык температура үзгәрми диярлек $t = +24... +26°C$, еллык явым-төшем күләме 2000—3000 мм һәм алар ел буена тигез бүленәләр. Бу климат — ...

1. Экваториаль климат.
2. Субэкваториаль климат.
3. Дымлы тропик климат.

6. Явым-төшемнең аз булуы нинди атмосфера басымы өлкәләре белән бәйле?

1. Түбән басым өлкәләре.
2. Югары басым өлкәләре.

7. Африкада һәм бөтен җир шарында иң озын елга — ...

1. Конго.
2. Нил.
3. Замбези.

8. Бу күлнең мәйданы үзгәрүчән. Аның мәйданы явым-төшемнәргә һәм үзенә агып төшә торган елгаларның ташуына бәйле. Бу күл — ...

1. Чад күле.
2. Виктория күле.
3. Ньяса күле.

9. Африкада кайсы табигый географик зона өчен түбәндәге үзенчәлекләр хас: коры тропик климат, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы бик ярлы. Бу — ...

1. Дымлы экваториаль урманнар (гилея) зонасы.
2. Саванналар һәм сирәк урманнар зонасы.
3. Тропик чүлләр зонасы.

10. Бу ил Африка илләре арасында мәйданы буенча иң зурысы. Аның табигате бик үзенчәлекле: монда Африканың бөтен табигый зоналары бар диярлек (төньякта тропик чүлләрдән башлап көньякта тропик дымлы урманнарга кадәр). Башкаласы — Хартум шәһәре. Бу ил — ...

1. Ливия.
2. Тунис.
3. Судан.

4 нче вариант

1. Африка ярларында мәйданы буенча иң зур утрау — ...

1. Сан-Томе утравы.
2. Мадагаскар утравы.
3. Занзибар утравы.

2. Африканың кайсы өлеше абсолют биеклеге буенча 1000 м дан артыграк?

1. Төньяк һәм Көнбатыш Африка.
2. Көньяк һәм Көнчыгыш Африка.

3. Рельеф формасына иң биек тау түбәсен тәңгәл китереп җавап бирегез:

Рельеф формасы:	Иң биек тау түбәсе:
1. Көнчыгыш Африка таулыгы.	А. Тубкаль тавы.
2. Эфиопия таулыгы.	Б. Килиманджаро вулканы.
3. Атлас таулары.	В. Рас-Дашэн тавы.

4. Ни өчен Африканың күп өлешендә тигезлек рельефы өстенлек итә?

1. Чөнки материкның өслеге кристаллик һәм утырма токымнардан тора.
2. Материкның нигезендә борынгы Африка-Гарәбстан платформасы ята.

5. Сахара чүле климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: һава температурасының тирбәлүе бик зур (уртача $t_{г}$ = +16°С, $t_{и}$ = +32°С), еллык явым-төшем күләме 100—200 мм дан артмый, даими (пассатлар) һәм җирле (сәмум) җилләр өстенлек итә. Бу — ...

1. Экваториаль климат.
2. Тропик чүлле климат.
3. Тропик дымлы климат.

6. Субэкваториаль климатлы урыннарда кайсы сезонда явым-төшем иң күп була?

1. Җәй көне.
2. Кыш көне.

7. Зәңгәр Нил елгасы кайсы күлдән башлана?

1. Виктория күленнән.
2. Чад күленнән.
3. Тана күленнән.

8. Африкада иң биек шарлавык (933 м) кайсы елгада урнашкан?

1. Замбези елгасында.
2. Тугела елгасында.
3. Оранжевая елгасында.

9. Дөяләр, кәлтәләр, еланнар, кыр кәҗәләре, чүл бүреләре (шакал), төлкеләр һ. б. кайсы табигый зонада яши?

1. Дымлы экваториаль урманнарда (гилеяләрдә).
2. Саванналарда һәм сирәк урманнарда.
3. Тропик чүлләрдә.

10. Бу ил — үзәк Африка илләре арасында иң зурысы. Илнең яртысыннан күбрәк өлешен дымлы тропик (экваториаль) урманнар алып тора. Монда Африканың иң тулы сулы елгасының тамагы урнашкан. Башкаласы — Киншаса шәһәре. Бу ил — ...

1. Ангола.
2. Заир.
3. Конго.

1 нче вариант

1. Атамага географик объектны тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик объект:
1. Арнемленд.	А. Утрау.
2. Тасмания.	Б. Материк.
3. Австралия.	В. Ярымутрау.

2. Австралия материгының иң зур өлеше урнашкан геологик нигез — ...

1. Борынгы җыерчыклану өлкәсе.
2. Борынгы платформа.

3. Австралиянең төньяк өлеше климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: җәй көне — ЭҺМ, кыш көне — ТҺМ, еллык явым-төшем күләме 500—2000 мм. Иң күп явым төшем җәй көне була. Бу — ...

1. Субэкваториаль климат.
2. Тропик климат.
3. Субтропик климат.

4. Кайсы климатик пояс Австралиянең иң зур өлешен алып тора?

1. Субэкваториаль.
2. Тропик.
3. Субтропик.

5. Австралиянең органик дөньясының үзенә генә хас бер төрлелеген нәрсә белән аңлатырга була?

1. Иң коры материк.
2. Австралия һәм аның янындагы утраулар башка материклардан бик күптән аерылган һәм материкның органик дөньясы озак вакытлар буенча аерым яшәгән.
3. Бозлыклар һәм вулканнар булмаган.

2 нче вариант

1. Атамасы белән географик урынын тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик урыны:
1. Йорк борыны.	А. Австралиянең көньяк ноктасы.
2. Стип-Пойнт борыны.	Б. Австралиянең көнчыгыш ноктасы.
3. Байрон борыны.	В. Австралиянең көнбатыш ноктасы.
4. Көньяк-Көнчыгыш борыны.	Г. Австралиянең төньяк ноктасы.

2. Зур Субүләр сырт кайсы җыерчыклану өлкәсенә туры килә?

1. Борынгы җыерчыклану өлкәсенә.
2. Яңа җыерчыклану өлкәсенә.

3. Яңа Гвинея утравының төньяк өлеше климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: еллык явым-төшем күләме 3 000 мм дан артык, һәм ул ел буена тигез бүленә, уртача еллык һава температурасы үзгәрми t = +24... +26°C. Бу климат — ...

1. Экваториаль.
2. Субэкваториаль.
3. Тропик.

4. Австралиянең төньяк өлеше нинди климатик поясста урнашкан?

1. Субэкваториаль пояста.
2. Тропик пояста.
3. Субтропик пояста.

5. Австралиянең дәүләт гербында кенгерә белән бергә ниндидер хайван төшерелгән. Бу — ...

1. Сазкойрык.
2. Тәвә кошы эму.
3. Үрдәкборын.

3 нче вариант

1. Атамага географик объектны тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик объект:
1. Карпентария.	А. Диңгезе.
2. Мәрҗән.	Б. Бугазы.
3. Торрес.	В. Култыгы.

2. Зур Субүләр сырт биеклеге буенча кайсы тау төркеменә керә?

1. Биек таулар.
2. Урта биеклектәге таулар.
3. Тәбәнәк таулар.

3. Австралиянең зур өлеше климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: еллык явым-төшем күләме 250 мм гына, сезоннар буенча һава температурасы бик нык үзгәрә (уртача $t_г = +24...+32°C$, $t_и = +16°C$), даими җилләр — пассатлар өстенлек итә. Бу — ...

1. Субэкваториаль климат.
2. Тропик дымлы климат.
3. Тропик чүлле климат.

4. Тасмания утравының көньяк өлеше кайсы климатик пояста урнашкан?

1. Тропик пояста.
2. Субтропик пояста.
3. Уртача пояста.

5. Бу хайван — җир шарында иң гади төзелешле имезүчеләрнең берсе. Ул — ...

1. Аю коала.
2. Ехидна.
3. Көнгерә.

4 нче вариант

1. Атамага географик объектны тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик объект:
1. Фиджи	А. бугазы.
2. Зур Австралия	Б. диңгезе.
3. Басс	В. култыгы.

2. Борынгы платформадан башка Австралия материгының нигезендә тагын нинди тектоник структура урнашкан?

1. Борынгы җыерчыклану өлкәсе.
2. Яңа җыерчыклану өлкәсе.

3. Зур Субүләр сыртының көнчыгыш битләре климатының күп өлешенә түбәндәге үзенчәлекләр хас: ТҺМ, уртача $t_г = +24°C$, $t_ц = +16°C$, еллык явым-төшем күләме 500—2 000 мм һәм ул ел буена тигез бүленә, ә җәй көне максималь була. Бу — ...

1. Субэкваториаль климат.
2. Тропик дымлы климат.
3. Тропик чүлле климат.

4. Австралиянең көньяк өлеше кайсы климатик пояста урнашкан?

1. Субэкваториаль пояста.
2. Тропик пояста.
3. Субтропик пояста.

5. Скрэб нәрсә ул?

1. Биек үләнле (кыяклы) әрәмәлекләр.
2. Коры куаклыклардан торган әрәмәлекләр.

1 нче вариант

1. Атамага географик урынын тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик урыны:
1. Кабу-Бранку борыны.	А. Көньяк Американың иң төньяк ноктасы.
2. Фроуэрд борыны.	Б. Көньяк Американың иң көньяк ноктасы.
3. Гальинас борыны.	В. Көньяк Американың иң көнбатыш ноктасы.
4. Париньяс борыны.	Г. Көньяк Американың иң көнчыгыш ноктасы.

2. Көньяк Америка материгының көнчыгыш өлеше нигезендә нинди платформа ята?

1. Африка-Гарәбстан платформасы.
2. Австралия платформасы.
3. Көньяк Америка платформасы.

3. Түбәндә санап киткән тау системаларының кайсылары Анд таулары белән бер үк вакытта (бертөрле җыерчыклану чорында) барлыкка килгән?

1. Атлас таулары (төньяк өлеше).
2. Кап таулары.
3. Зур Субүләр сырт.

4. Көньяк Америка климатына нинди океан зуррак йогынты ясый?

1. Тын океан.
2. Атлантик океан.
3. Һинд океаны.

5. Көньяк Американың көньяк-көнбатыш өлешенең климатына түбәндә күрсәтелгән үзенчәлекләр хас: УҺМ, уртача $t_{\text{г}} = +8^{\circ}C$, $t_{\text{[illegible]}} = 0... +6^{\circ}C$, еллык явым-төшемнең күләме 2000—3000 мм, һәм ул ел буена тигез бүленә, ел дәвамында көнбатыш җилләр өстенлек итә. Бу — ...

1. Уртача континенталь.
2. Уртача диңгез.
3. Экваториаль климат.

6. Җир шарында һәм Көньяк Америка материгында иң тулы сулы елга — ...

1. Амазонка елгасы.
2. Ориноко елгасы.
3. Парана елгасы.

7. Көньяк Америкада мәйданы буенча иң зур күл — ...

1. Титикака күле.
2. Маракайбо күле.

8. Бразилия яссы таулыгының зур өлешендә нинди табигый зона өстенлек итә?

1. Дымлы экваториаль ураманнар (сельва) зонасы.
2. Саванна (кампос) зонасы.
3. Далалар (пампа) зонасы.

9. Көньяк Американың бу табигый зонасына түбәндәге үзенчәлекләр хас: ул экваторның ике ягына да урнашкан, ел дәвамында җылы һәм дымлы климат, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы бик бай, кызгылт сары ферралит туфраклар өстенлек итә. Бу — ...

1. Дымлы экваториаль урманнар (сельва) зонасы.
2. Саванна (кампос) зонасы.
3. Далалар (пампа) зонасы.

10. Бу дәүләт Көньяк Американың төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Аның башкаласы — Санта-Феде-Богота шәһәре. Испан яулап алучылары бу илне «әкияти байлыклар иле» дип атаганнар. Ә 1863 елдан хәзергә ка-

дәр ул материкны ачкан сәяхәтчеләрдән берсенең исемен йөртә. Бу ил — ...

1. Суринам. 2. Венесуэла. 3. Колумбия.

2 нче вариант

1. Атамага географик объектны тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик объект:
1. Кариб	А. каналы.
2. Панама	Б. бугазы.
3. Магеллан	В. диңгезе.

2. Анд таулары нинди җыерчыклану чорында барлыкка килгәннәр?

1. Борынгы.
2. Урта чор.
3. Яңа.

3. Көньяк Америка платформа бөгелешләренә нинди рельеф формасы туры килә?

1. Амазонка түбәнлеге.
2. Гвиана яссы таулыгы.

4. Әгәр бу территория эчендә уртача гыйнвар һәм июль температурасы +24... +26°С булса, бу — ...

1. Ла-Плата түбәнлеге.
2. Патагония өлкәсе.
3. Амазонка түбәнлеге.

5. Көньяк Американың иң көнбатыш өлеше (экватордан көньяк тропикка кадәр) климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: ТҺМ, уртача $t_г$ = +16... +24°С, ә $t_и$ = +8°С. Еллык явым-төшем күләме 100 мм дан да артмый. Бу — ...

1. Субэкваториаль климат.
2. Тропик чүлләр климаты.
3. Субтропик континенталь климат.

6. Җир шарында һәм Көньяк Америка материгында иң биек шарлавык — ...

1. Анхель шарлавыгы.
2. Ниагара шарлавыгы.
3. Игуасу шарлавыгы.

7. Бу елгага түбәндә күрсәтелгән режим хас: июнь-июль айларында — су ташый, ә елгалардагы суның иң аз булган вакыты декабрь-гыйнвар айларына туры килә. Бу — ...

1. Амазонка елгасы.
2. Ориноко елгасы.
3. Парана елгасы.

8. Ла-Плата түбәнлегенең иң көньяк һәм көньяк-көнчыгыш өлешендә нинди табигый географик зона өстенлек итә?

1. Саванна (кампос).
2. Далалар (пампа).
3. Чүлләр һәм ярымчүлләр.

9. Көньяк Америкада бу табигый географик зонага түбәндәге үзенчәлекләр хас: субтропик поясста (тигез дымлану өлкәсе) урнашкан, уңдырышлы кызгылт кара туфраклар, үләнле үсемлекләр дөньясы һәм тиз йөгерә торган хайваннар өстенлек итә. Индеецлар телендә бу табигый зонаның исеме агачсыз киңлек дигәнне аңлата. Бу — ...

1. Дымлы экваториаль урманнар (сельва) зонасы.
2. Саванна (кампос) зонасы.
3. Далалар (пампа) зонасы.

10. Бу дәүләт Көньяк Американың көнбатыш өлешендә урнашкан, аның башкаласы — Лима шәһәре. Бу илнең территориясендә җир шарындагы иң тулы сулы Амазонка елгасы башлана, ә аның көньяк-көнчыгыш өлешендә иң биек тау күле — Титикаканың зур өлеше урнашкан. Илнең территориясен Американың борынгы бөек дәүләте — инк халыклары дәүләте биләгән (Американы Колумб ачканчы), башкаласы Куско шәһәре булган. Бу — ...

1. Эквадор. 2. Перу. 3. Чили.

3 нче вариант

1. Башка көньяк материклар белән чагыштырганда, бу континентта табигый зоналар күптөрлелегенең бер сәбәбе — ул материкның төньяктан-көньякка таба, яки экватордан уртача киңлекләргә кадәр сузылуы. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Көньяк Америка.
3. Австралия.

2. Анд таулары нинди ике литосфера плитасы орыну нәтиҗәсендә барлыкка килгән?

1. Көньяк Америка һәм Африка-Гарәбстан литосфера плиталары.
2. Көньяк Америка һәм Тын океан литосфера плиталары.

3. Көньяк Америка платформасының калку урыннары нинди рельеф формасына туры килә?

1. Амазонка түбәнлеге.
2. Гвиана яссы таулыгы.

4. Атамага (территориягә) еллык явым-төшем күләмен тәңгәл китереп җавап бирегез:

Территория:	Еллык явым-төшем:
1. Амазонка түбәнлеге.	А. 100 мм дан азрак.
2. Патагония өлкәсе.	Б. 2000—3000 мм.
3. Атакама чүле.	В. 100—250 мм.

5. Көньяк Американың көньяк-көнчыгыш өлеше климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: УҺМ, уртача $t_г = +16°C$, $t_и = 0°C$ (минималь температура июльдә −30°C булырга мөмкин), еллык явым төшем күләме 100 мм дан 250 мм га кадәр. Кыш көне салкын һәм кар аз, ә җәй көне җылы һәм коры. Ел дәвамында көнбатыш җилләр өстенлек итә. Бу — ...

1. Уртача континенталь климат.
2. Уртача диңгез климат.
3. Субтропик континенталь климат.

6. Индеецлар телендә бу шарлавыкның исеме «зур су» дигәнне аңлата. Шарлавыкның географик координатлары 25°30 к.к., 54° кб. оз.. Бу — ...

1. Анхель шарлавыгы.
2. Ниагара шарлавыгы.
3. Игуасу шарлавыгы.

7. Бу елгага түбәндәге режим хас: декабрь-гыйнвар айларында су ташый, ә елгалардагы суның аз булган вакыты — июнь-июль айларында. Бу — ...

1. Амазонка елгасы.
2. Ориноко елгасы.
3. Парана елгасы.

8. Патагониянең зур өлешендә нинди табигый географик зона өстенлек итә?

1. Саванна (кампос).
2. Далалар (пампа).
3. Чүлләр һәм ярымчүлләр.

9. Көньяк Американың бу табигый географик зонасына түбәндәге үзенчәлекләр хас: субэкваториаль климат; кызыл ферралит һәм көрән-кызыл ферралит туфраклар; үсемлек төркемчәләре (кебрачо, мангабейра һ. б.) һәм хайваннар (вак боланнар, кыргый дуңгызлар, бронялылар, кырмыскаашар, тәвә кошы нанду һ. б.) дөньясы, Африканың шул ук табигый зонасы белән чагыштырганда шактый ярлы. Бу — ...

1. Дымлы экваториаль урманнар (сельва) зонасы.
2. Саванна (кампос) зонасы.
3. Далалар (пампа) зонасы.

10. Бу дәүләт Көньяк Американың Тын океан яры буйлап тар тасма кебек сузылган, башкаласы — Сантьяго шәһәре. Илнең төньяк өлешендә җир шарында иң коры чүл — Атакама чүле урнашкан. Индеецлар телендә бу илнең исеме «салкын» дигәнне аңлата. Бу дәүләт — ...

1. Эквадор. 2. Перу. 3. Чили.

4 нче вариант

1. Бу материкның бөтен нокталары көнбатыш озынлыкта ята. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Көньяк Америка.
3. Австралия.

2. Көньяк Американың иң биек тау түбәсе — ...

1. Бандейра тавы.
2. Уаскаран тавы.
3. Аконкагуа тавы.

3. Көньяк Америкадагы платформа бөгелешләренә нинди рельеф формасы туры килә?

1. Ла-Плата түбәнлеге.
2. Бразилия яссы таулыгы.

4. Атамага белән еллык явым-төшем режимын тәңгәл китереп җавап бирегез:

Территория исеме:	Еллык явым-төшем:
1. Амазонка түбәнлеге.	А. Июнь-июль — max, декабрь-гыйнвар — min.
2. Бразилия яссы таулыгы.	Б. Ел буе бертигез.
3. Гвиана яссы таулыгы.	В. Декабрь-гыйнварь — max, июнь-июль — min.

5. Ла-Плата түбәнлегенең көньяк һәм көньяк-көнчыгыш өлеше климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: кыш көне — УһМ, җәй көне — ТһМ, уртача $t_г = +24°C$, ә $t_и = +8°C$, еллык явым-төшем күләме 500 мм дан 1000 мм га кадәр һәм ел эчендә бертигез бүленә. Бу — ...

1. Субтропик урта диңгез климаты.
2. Субтропик континенталь климат.
3. Субтропик тигез дымлы климат.

6. Җир шарында иң биек тау күле — ...

1. Титикака.
2. Маракайбо.
3. Танганьика.

7. Көньяк Американың кайсы елгасына ел әйләнәсендә тулы сулылык хас?

1. Амазонка.
2. Ориноко.
3. Парана.

8. Амазонка елгасы бассейнының зур өлешендә нинди табигый географик зона өстенлек итә?

1. Дымлы экваториаль урманнар (сельва).
2. Саванна (кампос).
3. Далалар (пампа).

9. Көньяк Американың көньяк-көнчыгыш өлеше табигый зонасына түбәндәге үзенчәлекләр хас: уртача континенталь (еллык явым-төшем күләме 100 мм дан 250 мм га кадәр) климат, аз уңдырышлы көрән туфраклар, үсемлекләр дөньясы — кыяклы үлән һәм чәнечкеле куаклар. Хайваннар дөньясы бай түгел (кимерүче хайваннар, саз кондызы, бронялылар һ. б.). Бу — ...

1. Далалар (пампа) зонасы.
2. Ярымчүлләр зонасы.
3. Катнаш урманнар зонасы.

10. Бу дәүләт Көньяк Американың төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан, аның башкаласы — Кито шәһәре. Испан телендә бу илнең исеме «экватор» дигәнне аңлата. Башкаласыннан көньякка таба җир шарында иң биек, ата торган Котопахи вулканы (5897 м) урнашкан. Кечуа индеецлары телендә аның исеме «ялтырый торган биек тау» дигәнне аңлата. Бу ил — ...

1. Эквадор.
2. Перу.
3. Чили.

1 нче вариант

1. Кайсы материкны көнбатыштан — Атлантик, ә көнчыгыштан Һинд океаны сулары юа?

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

2. Бу материкның барлык нокталары көнбатыш озынлыкта ята. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

3. Бу материкның рельефына түбәндәге үзенчәлекләр хас: көнчыгышта — тигезлек рельеф формалары, ә көнбатышта тау рельеф формалары өстенлек итә. Бу — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

4. Җир шарында иң биек материк — ...

1. Африка.
2. Антарктида.
3. Көньяк Америка.

5. Иң дымлы материк — ...

1. Австралия.
2. Антарктида.
3. Көньяк Америка.

6. Эсселек полюсы (Триполи шәһәре, күләгәдә һава температурасы +53° С җитә) кайсы материкта урнашкан?

1. Африкада.
2. Австралиядә.
3. Көньяк Америкада.

7. Бу материкта җир өсте сулары гадәти хәлдә очрамый диярлек. Бу материк — ...

1. Австралия.
2. Антарктида.
3. Африка.

8. Бу елга күп сулы булуы белән җир шарында икенче урынны алып тора, ә көнчыгыш ярымшарда — беренче. Аның бассейны кайсы материкта урнашкан?

1. Африкада.
2. Австралиядә.
3. Көньяк Америкада.

9. Кайсы материкта иң гади төзелешле имезүчеләр — ехидна һәм үрдәкборын яши?

1. Африкада.
2. Австралиядә.
3. Көньяк Америкада.

10. Кайсы материкта бер генә дәүләт урнашкан?

1. Австралиядә.
2. Антарктидада.
3. Көньяк Америкада.

2 нче вариант

1. Кайсы материкны көнбатыштан Һинд океаны, ә көнчыгыштан Тын океан сулары юа?

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

2. Бу материкның барлык нокталары да көньяк киңлектә ята. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Антарктида.
3. Көньяк Америка.

3. Бу материкта тигезлекле рельеф формалары (түбәнлекләр һәм калкулыклар) өстенлек итә, ә көнчыгышында уртача биеклектәге таулар урнашкан. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

4. Килиманджаро вулканы — бу материкның иң биек тау түбәсе. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Антарктида.
3. Көньяк Америка.

5. Җир шарында иң эссе материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

6. Көньяк материклар арасында уртача климатик пояста урнашкан бердәнбер материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

7. Бу материкның җир өсте сулары (эчке су агышы өлкәләреннән башка) ике океан бассейнына карый һәм зуррак өлеше — Атлантик, ә кечерәк өлеше Тын океан бассейнына керә. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

8. Бу күлне «Байкалның сеңлесе» дип йөртәләр, чөнки җир шарында тирәнлеге буенча ул икенче урында тора. Бу күл кайсы материкта урнашкан?

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

9. Бу материкта яши торган хайваннар арасында иң билгелеләре: тапир, бронялылар, тәвә кошы нанду, ягуар, анаконда, пиранья балыгы, кондор, иренчәк, лама, кырмыскаашар һ. б. Бу хайваннар кайсы материкта яшиләр?

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

10. Бу материкта даими рәвештә яшәүче халык юк. Бу материк — ...

1. Австралия.
2. Антарктида.
3. Көньяк Америка.

3 нче вариант

1. Кайсы материкны көнбатыштан — Тын океан, ә көнчыгыштан Атлантик океан сулары юа?

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

2. Бу материкның барлык нокталары көнчыгыш озынлыкта яталар. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

3. Кайсы материкта тигезлекле рельеф формалары (калкулыклар һәм яссы таулыклар) өстенлек итәләр?

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

4. Бу материкның иң биек тау түбәсе — Аконкагуа тавы. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Антарктида.
3. Көньяк Америка.

5. Җир шарында иң салкын материк — ...

1. Африка.
2. Антарктида.
3. Көньяк Америка.

6. Кайсы материкның зур өлеше тропик климатик пояста (ТКП) урнашкан?

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

7. Бу материк территориясенең яртысыннан артыграк өлеше эчке су агышы бассейнына керә. Бу территориягә вакытлыча корый торган елгалар челтәре — криклар хас. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

8. Җир шарында иң озын елга кайсы материкта урнашкан?

1. Африкада.
2. Антарктидада.
3. Көньяк Америкада.

9. Бу материкның хайваннары арасында иң күп очраучылары — пингвиннар. Океан суларында тюлень (су эте), зәңгәр кит, кашалот, касаткалар яши, ә яр буйларында үләксә акчарлакларын очратырга мөмкин. Бу материк — ...

1. Австралия.
2. Антарктида.
3. Африка.

10. Бу материк халкы күп гасырлар коллар чыганагы булган. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

4 нче вариант

1. Көньяк материклар арасында бу материкны гына өч океанның да (Тын, Атлантик һәм Һинд) сулары юа. Бу материк — ...

1. Австралия.
2. Антарктида.
3. Көньяк Америка.

2. Бу материкның барлык ноктылары да көньяк киңлектә ята. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

3. Кайсы материкның нигезендә ике тектоник өлкә: көнбатышында — яңа җыерчыклану өлкәсе, ә көнчыгышында борынгы платформа ята?

1. Африка.
2. Антарктида.
3. Австралия.

4. Кайсы материкта хәзер ата торган вулканнар һәм хәзерге заман бозланышы юк?

1. Африкада.
2. Антарктидада.
3. Австралиядә.

5. Җир шарында иң коры материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

6. Бу материкта экваториаль климатик поястан башка климатик пояслар кабатланалар. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

7. Планетадагы бөтен төче суның 80% ы кайсы материкта җыелган?

1. Австралиядә.
2. Антарктидада.
3. Көньяк Америкада.

8. Җир шарында иң тулы сулы елга кайсы материкта ага?

1. Африкада.
2. Австралиядә.
3. Көньяк Америкада.

9. Бу материкның хайваннар дөньясы күптөрле: монда кәрлә бегемотлар, окапилар, жирафлар, мөгезборыннар, филләр, арысланнар, төрле кошлар (тәвә кошы, марабу, секретарь), шимпанзе, горилла һ. б. яшиләр. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

10. Күп еллар дәвамында бу материк территориясе Европаның ике иле — Испания һәм Португалия арасында бүленгән була. Бу материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Көньяк Америка.

1 нче вариант

1. Атамага географик объектны тәңгәл китереп җавап бирегез.

Атама:	Географик объект:
1. Мексика	А. каналы.
2. Шелихов	Б. диңгезе.
3. Саргасс	В. култыгы.
4. Панама	Г. бугазы.

2. Аппалач таулары кайсы җыерчыклану чорында формалашкан?

1. Борынгы.
2. Урта.
3. Яңа.

3. Бу тигезлекнең күп өлеше елга китермәләреннән хасил булган. Бу — ...

1. Олы тигезлекләр.
2. Үзәк тигезлекләр.
3. Миссисипи түбәнлеге.

4. Төньяк Америка материгында кайсы климатик пояс юк?

1. Арктик климатик пояс.
2. Тропик климатик пояс.
3. Экваториаль климатик пояс.

5. Атлантика яр буе түбәнлеге климатының күп өлешенә түбәндә күрсәтелгән үзенчәлекләр хас: кыш көне УҺМ, җәй көне — ТҺМ, уртача $t_{я}$ = +8°C, $t_{и}$ = +24°C, еллык явым-төшем микъдары 1000—2000 мм, һәм ул ел буена тигез диярлек бүленә, сезонлы җилләрнең йогынтысы шактый сизелә: җил җәен — диңгездән материкка таба, ә кышын — материктан диңгезгә таба исә. Бу — ...

1. Муссонлы субтропик климат.
2. Субтропик континенталь климат.
3. Субтропик урта диңгез климаты.

6. Төньяк Америка материгының иң тулы сулы елгасы — ...

1. Маккензи. 2. Миссисипи. 3. Колорадо.

7. Төньяк Америка материгының мәйданы буенча иң зур күле (җир шарында икенче урында) — ...

1. Зур Аю күле.
2. Югары күл.
3. Мичиган күле.

8. Төньяк Американың яр буенда урнашкан табигый зонага түбәндәге үзенчәлекләр хас: субарктик климат, сазлыклы туң туфраклар, мүклишайниклар һәм куакчыл үсемлекләр; сарык-үгезләр, ак төлке, төньяк боланы карибу, ак кыр тавыгы, ак ябалак яши, яр буенда моржлар һәм тюленьнар таралган. Бу — ...

1. Арктик чүлләр зонасы.
2. Тундра зонасы.
3. Тайга зонасы.

9. Калифорния ярымутравының күп өлешен кайсы табигый зона алып тора?

1. Ярымчүлләр һәм чүлләр.
2. Саванна.
3. Алмашынучан дымлы (муссонлы) урманнар.

10. Төньяк Америка материгының төньягында урнашкан илнең исеме Америка индеецлары телендә «авыл» дигәнне аңлата. Бу илнең башкаласы — Оттава шәһәре. Ул ил мәйданы буенча Россиядән кала икенче урында тора, бигрәк тә урманнарга, файдалы казылмаларга, кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләргә бай. Илнең көньягында уңдырышлы җирләр күп. Бу ил — ...

1. Америка Кушма Штатлары.
2. Канада.
3. Мексика.

2 нче вариант

1. Атамага географик объектны тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик объект:
1. Калифорния	А. бугазы.
2. Флорида	Б. утравы.
3. Лабрадор	В. култыгы.
4. Ньюфаундленд	Г. ярымутравы.

2. Кордильер таулары нинди ике литосфера плиталары бер-берсенә орыну нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр?

1. Көньяк Америка һәм Тын океан плиталары.
2. Төньяк Америка һәм Тын океан плиталары.
3. Төньяк Америка һәм Евразия плиталары.

3. Бу тигезлекнең күп өлеше бозлык утырмалары белән капланган. Бу — ...

1. Олы тигезлекләр.
2. Үзәк тигезлекләр.
3. Миссисипи түбәнлеге.

4. Төньяк Америка материгының климатына иң зур йогынты ясаучы океаннар — ...

1. Тын һәм Төньяк Боз океаннары.
2. Атлантик һәм Төньяк Боз океаннары.
3. Атлантик һәм Тын океаннар.

5. Юкатан ярымутравы климатына түбәндәге үзенчәлекләр хас: ел буена ТҺМ өстенлек итә, уртача $t = +24°C$, $t_{ц} = +24°C$, еллык явым-төшем күләме 500—2000 мм, ел буена пассат җилләре исә. Бу — ...

1. Тропик чүл климаты.
2. Тропик дымлы климат.
3. Субтропик муссонлы климат.

6. Миссисипи елгасының иң тулы сулы кушылдыгы — ...

1. Миссури елгасы.
2. Огайо елгасы.
3. Арканзас елгасы.

7. Континентның төньягында урнашкан бу елга елның күп өлешендә боз белән капланган. Суы җәй көне күтәрелә, ә кыш көне межень күзәтелә. Елга тамагын ачкан инглиз сәяхәтчесе исеме белән аталаган бу елга — ...

1. Миссисипи. 2. Маккензи. 3. Юкон.

8. Төньяк Америка материгының бу табигый зонасына түбәндәге үзенчәлекләр хас: континентның үзәк өлешен алып тора; уртача һәм субтропик поясның кара һәм каштан туфракларында үскән үлән үсемлекләре белән капланган урмансыз киңлекләр. Үсемлекләр арасында кыяклы үләннәр (тоз үләне, типчак, бизон үләне) өстенлек итә. Монда бизоннар, койотлар, төлкеләр, вак кимерүчеләр яшиләр. Бу — ...

1. Киң яфраклы урманнар зонасы.
2. Далалар (прерияләр) зонасы.
3. Алмашынучан дымлы (муссонлы) урманнар зонасы.

9. Төньяк Американың Олы күлләре кайсы табигый зонада урнашкан?

1. Тайга.
2. Катнаш һәм киң яфраклы урманнар.
3. Алмашынучан дымлы (муссонлы) урманнар.

10. Бу илнең исеме индеец кабиләләренең төп өлеше ацтеклар алласына бәйләнгән: ацтеклар, майя кабиләләре белән бергәләп, Колумб Америкасына кадәр иң югары цивилизацияле дәүләт төзегәннәр. Баш шәһәре — Мехико. Илнең табигате күптөрле. Монда яссы таулыклар, кактус куаклыклары, дымлы урманнар белән капланган сазлыклы түбәнлекләр, биек вулканнарның карлы түбәләре һәм эссе яр буйлары чиратлашып бара. Бу ил — ...

1. Америка Кушма Штатлары.
2. Мексика.
3. Гватемала.

3 нче вариант

1. Атамага географик урынын тәңгәл китереп җавап бирегез:

Атама:	Географик урыны:
1. Сент-Чарльз борыны.	А. Төньяк Американың иң көньяк ноктасы.
2. Мерчисон борыны.	Б. Төньяк Американың иң көнбатыш ноктасы.
3. Принц Уэльский борыны.	В. Төньяк Американың иң көнчыгыш ноктасы.
4. Марьято борыны.	Г. Төньяк Американың иң төньяк ноктасы.

2. Яр буе сыртлары белән якынча бер вакытта (бертөрле җыерчыклану чорында) барлыкка килгән тауларны атагыз:

1. Зур Субүләр сырты.
2. Анд таулары.
3. Кордильер таулары.

3. Төньяк Американың иң биек тау түбәсе — ...

1. Митчелл тавы.
2. Орисаба вулканы.
3. Мак-Кинли тавы.

4. Әгәр бу территориядә җәй һәм кыш температурасы +24°С булса, ул — ...

1. Лабрадор ярымутравы.
2. Флорида ярымутравы.
3. Юкатан ярымутравы.

5. Калифорния ярымутравы климатының күп өлешенә түбәндәге үзенчәлекләр хас: ел буена ТҺМ өстенлек итә, уртача $t_г = +16°С$, $t_ц = +24°С$, еллык явым-төшем күләме 100 мм дан 500 мм га кадәр, ел буена пассат җилләре исә. Бу — ...

1. Тропик чүлләр климаты.
2. Дымлы тропик климат.
3. Субтропик урта диңгез климаты.

6. Бу елга агымы буйлап 320 километрга Зур Каньон сузылган, каньон «диварлары» төрле яшьтәге һәм төстәге токымнардан тора. Ул елга — ...

1. Миссисипи.
2. Колумбия.
3. Колорадо.

7. Кайсы елга күбесенчә кар суларыннан туена?

1. Юкон елгасы.
2. Колорадо елгасы.
3. Рио-Гранде елгасы.

8. Уртача климатик пояста урнашкан бу табигый зонада күбрәк ылыслы агачлар (кара һәм ак чыршы, бизәмле ак чыршы, Америка карагае һәм нарат) өстенлек итә, алар вак яфраклы агач токымнары белән аралашкан. Көлсу туфраклар. Кара аю, Канада селәүчәне, Америка сусары, сасы сусар, поши, вапити боланы, бизоннар яшиләр. Бу табигый зона — ...

1. Тайга зонасы.
2. Катнаш урманнар зонасы.
3. Киң яфраклы урманнар зонасы.

